ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
"ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ГРАЖДАННАРЫНЫҢ
ЕГЕРМЕ ТУГЫЗЫНЧЫ ҖЫЕНЫ
КАРАР№3

«31» маЙ 2018 ел . Иннополис ш.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге
территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү һәм төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга карата бердәм таләпләр билгеләү, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге граждannар җыены
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен әлеге карарның кушымтасына ярашлы редакциядә расларга.

2. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2015 елның 03 июлендәге 5 номерлы VII гражданнар җыены «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре турында» 2015 ел, 3 июль, 5 нче номерлы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнарының VII Җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 12 ноябрь, 6 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Рәислек итүче,
Иннополис шәһәре Мэры Р.Р. Шагалеев